ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТУЙМА
ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

14 ноябрь 2025 ел № 2

2026 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлегенең
Туйма торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 март 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2025 елның 1 ноябрендәге 3 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. “2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан 500 сум күләмендә, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Туйма авылында юлларны кардан чистарту);

2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-81 тракторы өчен тагылма сатып алу, бәйрәм чаралары уздыру өчен сәхнә төзү)»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Енабердино авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Ю.Скворцова